СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 2-10 4нче август 2021 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегенең 2021 елның 1 яртыеллыгы өчен бюджет үтәлеше турында

2021 елның 1 яртыеллыгы өчен Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.5, 264.6 статьялары, Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 83, 84 статьялары нигезендә Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Статья 1. 2021 елның 1 яртыеллыгына бюджет үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 1922,61 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 1954,29 мең сум күләмендә расларга һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

2021 елның 1 яртыеллыгы өчен авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

авыл җирлеге бюджетының 2021 елның 1 яртыеллыгы өчен чыгымнарын әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча бүлү буенча;

2021 елның 1 яртыеллыгына авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә;

2021 елның 1 яртыеллыгына бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары әлеге карарга № 4 кушымта нигезендә билгеләнә.

Статья 2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Б.Ф.Хасанов/